**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында гражданнар җыены карары**

21.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Шәйморза авылында юлларны ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Тинчәле авыл җирлеге башлыгы _________ С.Р. Хәсәнов

Халык җыены секретаре _________ А.А. Гисмиева